ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты 2023 елның 1 апреленә кадәр кергән төзәтмәләрне исәпкә алып әлеге закон проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1849-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 90 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «яңаларын билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «яңаларын билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «билгеләүче яисә элек билгеләнгәнен үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) аерым гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда һәм (яисә) алар килеп чыкканда, югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә кабул ителергә тиешле булган яисә «Сугыш хәле турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасының бөтен территориясендә йә аның өлешендә кертелә торган аерым режимнар кысаларында күрелә торган чараларны тормышка ашыру максатларында әзерләнә торган.»;

3) $3^{1}$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^{1}$ статья. **Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе**

1. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү, федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Мәҗбүри таләпләрне билгеләүче норматив хокукый актлар нигезләмәләре тиешле елның йә 1 мартыннан, йә 1 сентябреннән, әмма, федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, тиешле норматив хокукый акт рәсми басылып чыккан көннән соң 90 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керергә тиеш.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезләмәләре террорчылык актларын кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү, илнең оборонасына һәм дәүләтнең иминлегенә куркынычны кисәтү максатларында кабул ителергә, аерым гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда һәм (яисә) алар килеп чыкканда кабул ителергә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә йә аның өлешендә югары әзерлек режимы яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә кабул ителергә тиешле норматив хокукый актларга, шулай ук җиңеп чыга алмаслык көч аркасында килеп чыккан хәлләрнең, ягъни, бу шартлардагы гадәттән тыш һәм каршы тора алмаслык хәлләрнең, аерым алганда эпидемияләрнең, эпизоотияләрнең, техноген аварияләрнең һәм һәлакәтләрнең, зыяннарын булдырмауга юнәлдерелгән норматив хокукый актларга карата кулланылмый.

4. Элек кабул ителгән норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертә торган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, җайга салу йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәдә бу үзгәрешләр физик һәм юридик затларның эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек өлкәсендә элек билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне башкару чыгымнарын киметү максатларында кертелә һәм яңа шартларны, чикләүләрне, тыюларны, бурычларны күздә тотмый дип билгеләнсә, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән сроклардан башка срокларда үз көченә керергә мөмкин.

5. Мәҗбүри таләпләр билгеләнгәндә түбәндәгеләр билгеләнергә тиеш:

1) мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеге (шартлар, чикләүләр, тыюлар, бурычлар);

2) мәҗбүри таләпләрне үтәргә тиешле затлар;

3) мәҗбүри таләпләрне билгеләү объектына карап:

а) үзләренә карата мәҗбүри таләпләр билгеләнүче гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек, башкарыла торган гамәлләр;

б) эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, гамәлләрне башкарганда мәҗбүри таләпләр куела торган затлар һәм файдаланыла торган объектлар;

в) үзләренә карата мәҗбүри таләпләр билгеләнүче эшчәнлекне гамәлгә ашыру, гамәлләрне башкару нәтиҗәләре;

4) мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү рәвешләре (дәүләт контроле (күзәтчелеге), административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, продукциянең туры килүен бәяләү һәм бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләре);

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләүче органнары.

6. Мәҗбүри таләпләрне Татарстан Республикасы Рәисе указлары белән билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

7. Мәҗбүри таләпләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары белән билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

8. Норматив хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне кулленуны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның фактагы йогынтысын бәяләү тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

9. Норматив хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне кулленуны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның фактагы йогынтысын бәяләү, җайга салучы орган тарафыннан үткәрелә.

10. Җайга салучы орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турындагы доклад әзерли. Әлеге тәртип белән шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү хакындагы докладны карау һәм мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның гамәлдә булу срогын озайту турында яисә мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның фактагы йогынтысын бәяләүне уздыру хакында карар кабул итү тәртибе билгеләнә.»;

4) 4 статьяның 5 өлешендә:

а) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү, шулай ук аларны федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясына тиешле үзгәрешләр кертә торган 2022 елның 19 декабрендәге 519-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә закон проекты белән җайга салу йогынтысын бәяләү процедурасыннан «Сугыш хәле турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы территориясендә кертелә торган аерым режимнар кысаларында күрелә торган чараларны тормышка ашыру максатларында әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларын төшереп калдырырга тәкъдим ителә.

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, закон проекты белән «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Закон) бөтен текстында республиканың иң югары вазыйфаи заты вазыйфасы исеменә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим ителә.

Моннан тыш, законнарны камилләштерү тәртибендә закон проекты белән Законда «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән мәҗбүри таләпләрне билгеләүнең аерым мәсьәләләрен, мондый норматив хокукый актларның үз көченә керү срокларын да кертеп, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мәҗбүри таләпләрне билгеләү тәртибен билгеләү өлешендәге вәкаләтләрен бүлешүне беркетергә тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү түбәндәгеләрне таләп итәчәк:

1) Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан мәҗбүри таләпләрне Татарстан Республикасы Рәисе указлары белән билгеләү тәртибен раслау турындагы указ чыгаруны;

2) «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларындагы мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 февралендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне.

**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.